ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.01.2025 п.г.т.Алексеевское № 17

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 31.03.2022 ел, № 113 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге «Муниципаль казна учреждениесенең штат расписаниесе турында» муниципаль берәмлекләр педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 14.08.2024 ел, № под-1430/24 һәм 22.11.2024 ел, № под-1950/24 «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 29.03.2022 № под-583/22 боерыгы белән расланган,Татарстан Республикасы «исем» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручылар хезмәтенә түләү шартлары турындагы Үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» боерыклары нигезендә

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 31.03.2022 ел, № 113 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге «Муниципаль казна учреждениесенең штат расписаниесе турында» муниципаль берәмлекләр педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карары белән расланган,муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификацион дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга база окладды күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яисә «дипломлы белгеч» квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| | | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br><br>Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 20329,0<br><br>20405,0 |

1.2. Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.8 - 1.12 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.8. | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбиясе өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Россия Федерациясенең тәрбия һәм мәгарифнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.12. | «Яшьлек һәм Профессионализм»күкрәк билгесе.». |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**